«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 28 декабрендәге № 73

««Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 28 апрелендәге 64 номерлы карарына үзгәреш кертү турында (2018 елның 06 июнендәге 70 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 84 номерлы, 2019 елның 30 маендагы 106 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 6 номерлы, 2022 елның 8 ноябрендәге 66 номерлы карарлар редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының,муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының, контроль-хисап палатасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү турында»2022 елның 12 декабрендәге 118 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында"2018 елның 28 апрелендәге 64 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге

"муниципаль берәмлеге Советының 06.06.2018 №70, 15.11.2018 №84, 30.05.2019 № 106, 21.09.2020 № 6, 08.11.2022 №66 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмәдә

2 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) | |
|---|---|---|
| | 11 төркем (халык саны 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр ) | 12 төркем (халык саны 1,5 меңгә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 039 | 17 390 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 13 681 | 12 689 |

»;

2 статьяның 1 пунктының алтынчы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлеге булган муниципаль берәмлек башлыгына хезмәт өчен түләүнең 12 төркеме өчен айлык акчалата түләүдән тыш, , елына 9,26 айлык акчалата бүләкләүдән артыграк күләмдә айлык акчалата бүләкләү түләнә. Аларның урынбасарларына, айлык акчалата түләүдән тыш, елына 9,18 акчалата бүләкләүдән артык булмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү түләнә.»; (11 хезмәт хакы төркеме өчен башлыкка 10,36 айлык акчалата бүләк, урынбасарлар өчен 10,69)

2 статьяның 2 пунктының 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1)муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә вазыйфаи оклад, авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең кече төркеме белгече вазыйфаларына 12688 сум күләмендә .»;

2 статьяның 2 пунктының 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү;»;

3 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) тиешле хезмәт хакының 18 процентыннан артмаган айлык акчалата бүләкләү».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы
авыл җирлеге башлыгы,   Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе                                        Э.И. Байдамшин